Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

**2016 елның 22 декабре** **№ 185**

Россия Федерациясе Җир кодексының 56.6 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне гомуми принциплар белән оештыру турында» 06.19.2003 ел, 131-ФЗ Федераль законы, «Арча шәһәре»муниципаль берәмлегенең генераль планы нигезендә, Арча шәһәр Советының 9.12.2009 №449 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре үзәк өлешенең проект методик планлаштыру проекты нигезендә Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Җирле әһәмияттәге автомобиль куюу урынын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы, Арча мунидипаль районы, Арча шәһәре, Галактионов урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:09:010121:380 булган җир участогын милекчедән муниципаль милеккә сатып алырга.

2. Милекчегә җир участогы өчен 182 700 (йөз сиксән ике мең җиде йөз) сум 00 тиен түләү тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар кабул ителгәннән соң ун көн эчендә:

1) әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru);

2) әлеге карарны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://arsk.tatarstan. ru);

3) җир кишәрлегенең хокук иясенә әлеге карарның күчермәсен җибәрергә;

4) әлеге карарның күчермәсен милек һәм аның белән килешүләр күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы территориаль органга җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча шәһәре башкарма

комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймов